ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.08.2026 г. Заинск № 414

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 18 ноябрендәге 535 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында гражданнар оборонасы штабын төзү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 19 гыйнварындагы 7 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 18 ноябрендәге 535 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында гражданнар оборонасы штабын төзү турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 24 нче абзацта:

- "хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында халык өчен" сүзләрен төшереп калдырырга.;

- "оборона һәм" сүзләрен «оборона, кирәкле көчләрне җиһазлау һәм әзерләү» сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. 26 абзацта "хәрби конфликтлар вакытында яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында" дигән сүзләр "куркынычлар килеп чыгу нәтиҗәсендә" сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 35 абзацта "хәрби конфликтлар яки бу конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында" дигән сүзләр "куркынычлар килеп чыкканда" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

О.Р. Харитонова